**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ**
**И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ**
**РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

21.01.2014 29-п

Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү өчен гаризаларны карау тәртибен раслау турында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 16 ст., «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 35.3 ст., Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү өчен гаризаларны карау тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга (кушымтада бирелә).

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (Тронин В.А.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары Т.М.Акчуринга йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров

Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү өчен гаризаларны карау тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 10.1 статьясының 6 пунктының 6 абзацын, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 35.3 ст. гамәлгә ашырганда, гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында карарлар кабул ителгәндә монополиягә каршы таләпләрне үтәү максатларында эшләнгән.

2. Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында аларны геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибе.

2.1. Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү өчен файдалануга бирү Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба — Министрлык) боерыгы белән җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы белән килешенеп, җир асты байлыклары турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә расланган Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә (алга таба — Исемлек) кертелгән җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата гамәлгә ашырыла.

2.2. Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алу өчен гариза бирүче Министрлыкка гариза әзерли һәм җибәрә, аңа кушымта бирелә:

мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документлары күчермәләре (юридик затлар өчен);

соңгы хисап датасына торышы буенча мөрәҗәгать итүченең бухгалтерлык балансы күчермәсе;

гариза бирү датасына кадәр бер ай эчендә гариза бирүче счетлары буенча акчалар әйләнеше турында банк оешмаларыннан белешмәләр;

кредит яки кредит килешүләре күчермәләре (булган очракта); подряд килешүләренең күчермәләре (булган очракта);

кулланыла торган технологияләр турында белешмә, аларны тасвирлап, бораулау һәм тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чаралар исемлеге, аларның гариза бирүчегә яисә җәлеп ителә торган подрядчыга каравын дәлилләп;

мөрәҗәгать итүченең яисә подрядчылар сыйфатында җәлеп ителә торган оешмаларның штат расписаниесе күчермәсе; эшләрне башкарачак белгечләрнең квалификация дипломнары күчермәләре;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирү мизгеленә торышын чагылдыра торган һәм эшләрне башлауда планлаштырыла торган сроклар һәм җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турындагы белешмәләрне үз эченә алган аңлатма язуы;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе.

Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга яки оригиналлар күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

2.3. Министрлык тиешле дәүләт органнарыннан түбәндәге документларны мөстәкыйль рәвештә соратып ала:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан) өземтә;

гариза бирүченең салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп;

салым һәм җыемнар түләү буенча бурычлар булуы яки булмавы турында салым органнарыннан белешмә.

2.4. Әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылырга мөмкин.

2.5. Министрлык, кирәк булганда, мөрәҗәгать итүчедән килештерүче органнар документларында бәян ителгән белешмәләрне ачыклаучы өстәмә материаллар һәм белешмәләр соратып ала.

2.6. Җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү максатларында җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын алу өчен гариза Министрлык сайтында расланган исемлекне урнаштырганнан соң бирелә.

2.7. Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алу өчен расланган Исемлек сайтта беренче тапкыр яисә элегрәк расланган Исемлеккә өстәмәләр басылып чыкканнан соң утыз эш көне эчендә таләпләргә туры килә торган ике яки аннан күбрәк гариза теркәлгән булса, Министрлык мондый җир асты байлыклары кишәрлегенә карата файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм алу максатларында җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына билгеләнгән тәртиптә аукцион уздырылуын оештыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән сроктан соң бирелгән икенче һәм аннан соңгы гаризалар карауга кабул ителми.

3. Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, эзләү һәм чыгару максатлары исемлегенә кертелгән һәм аукцион нәтиҗәләре буенча тәкъдим ителә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген файдалануга бирү.

3.1. Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, эзләү һәм чыгару максатлары исемлегенә кертелгән һәм аукцион нәтиҗәләре буенча бирү өчен тәкъдим ителә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү максатларында файдалануга бирү әлеге аукционның бердәнбер катнашучысы гаризасы нигезендә бер катнашучының катнашуы сәбәпле гамәлдә булмаган дип танылганнан соң гамәлгә ашырыла.

3.2. Министрлык гариза керүгә бәйле рәвештә җир асты байлыклары кишәрлегеннән геологик өйрәнү, разведкалау һәм файдалы казылмалар чыгару максатларында файдалану хокукына аукцион тану турында карар кабул ителгән датадан алып биш эш көне эчендә мондый аукционның бердәнбер катнашучысына аукционны узмаган дип тану һәм мондый аукционда бердәнбер катнашучының хокукы турында, гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын үз акчалары исәбеннән алуга гариза бирү турында хәбәр җибәрә.

3.3. Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алу өчен, үз акчалары исәбеннән, әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне алган көннән алып утыз эш көне эчендә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына аукционның бердәнбер катнашучысы, әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән документларны үз эченә алырга тиешле гаризаны Министрлыкка җибәрә. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары буенча тәкъдимнәрендә әлеге кишәрлекнең җир асты байлыкларын геологик өйрәнү этабы өчен аукцион шартлары белән билгеләнгән эшләрнең төрләре һәм күләмнәрен, шулай ук аларны үткәрү срокларын үтәүгә ризалык булырга тиеш.

Әлеге пунктта күрсәтелгән срокларны бозып бирелгән гаризалар карауга кабул ителми.

4. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 14 статьясы нигезендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турындагы гаризаны кабул итүдә түбәндәге очракларда баш тарта: лицензия бирүгә гариза билгеләнгән таләпләрне бозып бирелгән, шул исәптән аның эчтәлеге конкурс яисә аукцион игълан ителгән шартларга туры килмәсә; гариза бирүче аңлы рәвештә үзе турында дөрес булмаган белешмәләр тапшырганда; гариза бирүче эшләрне нәтиҗәле һәм куркынычсыз уздыру өчен кирәкле финанс һәм техник чараларга, квалификацияле белгечләргә ия булуы яки ия булачагы турында дәлилләмәләр тапшырмаган очракта һәм тапшыра алмаса; әлеге мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгән очракта монополиягә каршы таләпләр үтәлмәсә.

5. Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларының түбән горизонтларын геологик өйрәнү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен, яисә әлеге ятмаларга якын территорияләрне геологик өйрәнү максатларында файдалануга бирү, мондый җир асты байлыклары кишәрлекләрен Исемлеккә керткәннән соң, кызыксынган затларның гаризалары нигезендә гамәлгә ашырыла.